№ 35 (1162), 25 август 2012 ел

хатын җенесендәге шайтаннардан сыгынам», – дигәнне аңлата. Бу доганы кылгач, сул аяк белән беренче атлап мунчага керергә. Әгәр инде бер җенестә булган затлар бергә мунча керәләр икән, ул вакытта һәр очракта һәрберсе кендек өстеннән тез астына кадәр кием киергә тиеш яки киң сөлге бәйләргә тиеш. Бу ислам динендәге гаурәт мәсьәләсен чишү юлы. Ислам дине буенча никахсыз ирләр һәм хатыннарга бергә мунча керү хәрәм. Ник дисәгез, бу эш Аллаһы Тәгалә куйган нормалардан читкә чыгу була. Хәләл җефетләр генә бергә мунча керә алалар.

Мунчада суны исраф (кирәгеннән тыш әрәм) итүдән саклануны искә төшереп китергә кирәк. Су тутырып алына торган савытка яртылаш кына тутырып алу мәслихәт (яхшы нәтиҗәгә китерә). Ник дисәгез, тулы итеп тутырып алган очракта юына башлагач яртысы түгелеп бетү ихтимал. Шулай ук мунчада кирәгеннән тыш озак утыруның да кирәге юк. Мунчага кергән саен ислам динендәге йолаларга туры килгән рәвештә госел алып чыгуны гадәткә кертсәгез, шул гадәтегезнең рәхәтен күрерсез. Ягъни мунчадан чыккач иркенләп намаз укып, дога кылып һәм Коръән укып була. Юынып бетереп, коенып, сөртенеп киенгәннән соң, мунчадан уң аяк белән атлап чыгу кирәк. Мунчадан чыкканнан соң: *«Гуфраанәкә»,* – диярге кирәк. Моның мәгънәсе: «Мәгъфирәтнең белән гафу ит», – дигәнне аңлата. Ягъни мин, Раббым, Сине анда зикер итеп искә алудан мәхрүм идем, шуңа күрә мине гафу итүеңне үтенеп сорыйм, дигән эчтәлекне аңлата. Кем инде бу доганы аз дип күрә, ул тагын өстәмә Пәйгамбәребез кылган башка догаларын куллана ала. Шуларның тагы бер мисалы: *«Әлхәмду лилләәһил ләзии гәәфәәни фии руухи үә җәсәдии»,* – дигән дога. Бу доганың мәгънәсе: «Минем җаныма һәм тәнемә гафият биреп саулык-сәламәтлек биргән Аллаһыга мактау», – дигәнне аңлата. Мунча кереп чыкканнан соң, дин әдәпләре буенча ике рәкәгать нәфел намазы уку, аннан соң Коръәннән Әлхәмд, Әлиф-ләм-мим, Кәфирун, Изәә җәә-ә нәсърул Лааһ, Куль һуал Лааһ, Фәләкъ һәм Нас сүрәләрен уку бик күркәм гамәлләрдән санала. Бу гореф-гадәт безнең татар бабаларыбызда бик таралган булган, без, кызганычка, мондый күркәм гадәтләр белән горурлану урынына аларны онытып барабыз.

Моннан соң, әлбәттә, бөтенесе җомгага хәзерләнеп, мунча кереп, госел коенып бетергәч, гаилә даирәсендә җимешләп чәй эчү дә мөселман өчен бик күркәм гадәт.

Аллаһы Тәгалә барчаларыбызга шушы сүзләрдән бу дөньяда да, ахирәттә дә файда, мәнфәгатьләрен алырга насыйп әйләсен.

**Рөстәм хәзрәт ВӘЛИУЛЛА.**

# Исламда 40 саны

“Тур тавында гыйбадәттә тору өчен Мусага Без 30 төн бирдек, ахырда аңа тагы унны өстәдек. Аллаһы тәгаенләгән вакыт 40 төн булды. Муса кардәше Һарунга: *«Халкыбыз арасында минем урынга җитәкче булып каласың. Аларны туры юлга үгетлә, юлдан язганнарга иярмә»,* – диде («әл-Әгъраф» сүрәсе, 142 нче аять).

Ун төн өстәп куюның мәгънәсен Исраил балаларын сынау өчен дип аңларга кирәк, дигән имам Бәкер. Пәйгамбәргә 40 көн һәм 40 төн вакыт бирелсә дә, аятьләрдә 40 төн турында гына сүз бара. Сәбәбе, бәлки, гыйбадәтләрнең төнлә үтәлүе, догаларның төнлә кылынуы белән аңлатыладыр. Борынгы календарьда вакыт ай калкуына карап исәпләнә торган була, ә ай, гадәттә, төннәрдә генә калка, төннәр санына карап көннәр билгеләнә.

40 саны диндә бик күп төрле серле күренешләр белән бәйле, төрле диннәрдә һәм төрле халыкларның мәдәниятендә ул аерым урын алып тора.

Пәйгамбәребезгә Аллаһының илчесе булу вазифасы 40 яшьлек вакытында тапшырыла.

Фатыйма туар алдыннан, аның тууына әзерлек көннәрендә Пәйгамбәребез 40 көн буе хатыны Хәдичәгә якын бармый. Бервакыт 40 көн дәвамында Пәйгамбәребезгә аятьләр килми тора. Нух заманында туфан алдыннан 40 көн буе яңгыр ява. Динебез тарихыннан билгеле: Исраил кавеме 40 ел буе барыр җиренә бара алмый чүл-далада каңгырып йөри.

Динебез безгә Пәйгамбәребезнең ким дигәндә 40 хәдисен өйрәнеп алырга һәм аларны башкаларга да өйрәтергә боера. Галимнәр диннең төрле өлкәсенә караган 40 хәдисне бергә туплап, бик күп китаплар язганнар.

*«Кайбер галимнәр – диннең төп нигезләре, икенчеләре – төрле тармаклары, өченчеләре – җиһад, дүртенчеләре – тыелып яшәү, бишенчеләре – әдәп, алтынчылары вәгазь-нәсыйхәт турында 40 хәдис җыйганнар»,* – дип язган Ән-Нәвәви. 40 хәдисне яттан белгән кеше кыямәт көнендә дин галимнәре – факиһләр белән бергә кубарылыр, дигән борынгылар.

40 яшькә җиткәндә кеше рухи камиллеккә ирешә, игелеккә юл тота, ата-анасының кадерен белә башлый.

Авыруларның баш очында 40 тапкыр «әл-Фатыйха» сүрәсе укылса, авыру савыгырга мөмкин, дип өйрәткән бабайлар.

Аракы эчкән кешенең намазы 40 көн буе кабул ителми торыр. Шулай булса да, намазны калдырырга ярамый.

Әгәр дә берәүнең үле гәүдәсе каршында 40 мөселман: «Бу яхшы кеше иде», – дип торса, мәрхүмнең гөнаһлары ярлыкануы мөмкин.

*(“Дин вә йола” газетасыннан)*





# Кеше кайгысына сөенмәү

Чын мөселман кеше башкаларның кайгысына сөенмәү кебек түбән сыйфатлардан ерак тора. Бер хәдистә Мөхәммәд галәйһиссәләм болай дигән: *“Кардәшеңнең кайгысына сөенмә, чөнки Аллаһы Тәгалә аңа рәхим-шәфкать кылырга, ә сиңа бәла-каза җибәрергә мөмкин”.*

Ислам рухын сеңдергән чын мөселман кеше кайгысына сөенми, киресенчә, аның хәлен җиңеләйтергә тырыша. Ислам рухыннан ерак торган, үч алырга яратучы, усал ниятле, явыз фикерле һәм гайбәт сөйләүче авыру рухлы кеше генә башкаларның кайгысына сөенә.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән: “Башына берәр кайгы төшкән кеше: *“Без үзебез дә, әһелебез дә һәм барча малыбыз да – Аллаһы Тәгаләнекедер һәм Аның хозурына кайтачакбыз. Ий, Аллаһым! Мин бу кайгым бәрабәренә булачак савапка өметләнәм, сабыр итүем бәрабәренә миңа савап бир, шушы кайгымны яхшылыкка әйләндер!”* – дип әйтсен.

Аллаһы Тәгаләгә тыныч вакытларыңда итагать кыл, бәндәчелек күрсәт, Ул сиңа мөшкеллеккә төшкән вакытларыңда ярдәм бирер.

Әгәр синең өчен дөнья тарайса – “Ә ләм нәшрах” сүрәсендәге сүзләрнең мәгънәләре турында уйла: бер авырлыкка – бер җиңеллек, авырлык – ике җиңеллек арасында килер. Бәс, моны исеңә төшерсәң – шул мизгелдә үк сиңа шатлык хисе килер.

**Көнләшү**

Мөселман шәхесенә хас булмаган сыйфатларның берсе - көнләшү.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән: *“Кешенең күңелендә дин һәм көнчелек бергә була алмый”.*

Ялганнан, хыянәттән, көнчелектән һәм явызлыктан азат, эчкерсез һәм саф күңелле булу – чын мөселман булуның билгеләре. Нәкъ менә шундый кешеләр генә ислам җәмгыятен төзи ала. Ә инде кешеләргә карата нәфрәтле, алардан көнләшеп һәм аларны алдап йөрүчеләрнең исламдагы бәяләре – күп вакытларын гыйбадәттә уздыруларына карамастан, бер тиен.

Авырсынып садака бирүчеләр түгел, бәлки, аны алучы кебек шатланып бирүчеләр – чын бай кешеләрдер.

Фәкыйрь вакытында саран булган кешенең баегач юмарт булуын өмет итмәгез.

*(“Татар дини календаре”ннан)*

***БӘЕТ***

Кадерле редакция хезмәткәрләре! Мин Похвистнево районының Яңа Мансур авылында яшәүче Шәмсегаләм Усманова булам. Бик күп уйланып йөргәннән соң, үзем иҗат иткән “Ана сагышы” бәетен редакциягә җибәрергә булдым.

“Бердәмлек”нең укучылары минем кайгымны аңларлар дип уйлыйм. Минем өч кызым һәм бер улым бар иде. Хәзерге көндә улым гына калды. Өч кызымны да Аллаһы Тәгалә Үзе янына алды.

Күңел түремнән чыккан хисләремне шигъри юлларга салып, “Бердәмлек” редакциясенә җибәрәм.

## Ана сагышы

*“Бисмиллә” дип башладым*
*Һәрбер эшнең башларын.*
*Балаларымны җырләгәч,*
*Җиңеләя башладым.*

*Өч кыз баламны җырлэдек,*
*Иң олысы илле өчтә.*
*Үткән чакта карар идем,*
*Каберләре бик эчтә.*

*Мәчет башында күгәрчен*
*Укый “Әлхәм” сүрәсен.*
*Балалардан калырга*
*Ходай язган күрәсең.*

*Бакчабызда гөлләр үсә*
*Коймаларга үрмәләп.*
*Балаларым кайта иде*
*Җәй көннәрен бергәләп.*

*Бакчабызда гөлләр үсә,*
*Чәчәкләрен өзә алмыйм.*
*Сабыр ит, дип әйтәләр,*
*Еламыйча түзә алмыйм.*

*Балаларымны үстергәндә*
*Авыр иде тормышлар.*
*Сабыр итәм, ни хәл итим,*
*Шулай булгач язмышлар.*

*Чишмәләргә баргач, күрәм*
*Чиста суның агышын.*
*Саргайтты нурлы йөзләрне*
*Балаларның сагышы.*

*Төнне тышка чыккач, күрәм*
*Матур айның яктысын.*
*Күзләремнең нурын алды*
*Балаларның кайгысы.*

*Чишмәгә барыр идем,*
*Суларын алыр идем.*
*Әгәр кайтса балаларым,*
*Озата барыр идем.*

*Эчләремдә утлар яна,*
*Төтеннәре күренми.*
*Гүр туфрагына басмыйча*
*Хәсрәтләрем сүрелми.*